**РАСЛЫЙМ**

Россия ислам институты ректоры

Р.М. Мөхәммәтшин

______________________

**РАСЛЫЙМ**

Татарстан Республикасы Мөфтие

К.И. Сәмигуллин

______________________

**Татар теле, әдәбияты һәм татар халкы тарихы буенча дини уку йортлары студентлары арасында IV республикакүләм олимпиаданың нигезләмәсе**

## 1. Олимпиаданың гомуми нигезләре

1.1. Татар теле, әдәбияты һәм татар халкы тарихыннан республикакүләм олимпиада Татарстан урта һөнәри һәм югары мөселман уку йортлары студентлары арасында Россия ислам институты инициативасы һәм ярдәмендә, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте белән берлектә уздырыла.

1.2. Олимпиада татар телен, әдәбиятын һәм татар халкы тарихын өйрәнү, саклау һәм үстерү өчен өстәмә шартлар тудыру, яшь буында телне өйрәнүгә кызыксыну уяту, татар мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү, тел һәм сөйләм культурасын камилләштерүне күздә тота.

1.3. Олимпиаданың максатлары:

- студентларда телне өйрәнүгә кызыксыну уяту, аңа хөрмәт тәрбияләү, милли үзаң формалаштыруга ярдәм итү;
- талантлы яшьләрне барлау;
- татар телен, әдәбиятын һәм татар халкы тарихын өйрәнүне пропагандалау;
- студентларны эзләнү-тикшеренү эшенә тарту.

1.4. Олимпиадада Татарстан Республикасы урта һөнәри һәм югары мөселман уку йортларында көндезге бүлектә белем алучы 25 яшькә кадәрге студентлар катнаша ала. Татар теле һәм әдәбияте юнәлешендә махсус урта һөнәри яисә югары белеме булган студентлардан олимпиадага заявкалар кабул ителми.

1.5. Олимпиаданы оештыручылар: Россия ислам институты, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте.

## 2. Олимпиаданы оештыру һәм уздыру

2.1. Олимпиада өч юнәлештә бер турда уздырыла: татар теле, татар әдәбияты һәм татар халкы тарихы.

2.2. **Татар теленнән олимпиада** язма формада үткәрелә. Ул тесттан һәм аерым биремнәрдән гыйбарәт.

2.2.1. Тест үз эченә фонетика, лексикология, морфология, синтаксис һәм пунктуациягә кагылышлы сорауларны ала һәм студентларның теоретик белемнәрен, аларны практикада куллана белү дәрәҗәсен ачыклауны максат итеп куя.

2.2.2. Биремнәр студентның язма сөйләм мөмкинлекләрен, тел байлыгын, сөйләмнең эзлеклелеген, аңлаешлылыгын ачыклауны күздә тота.

2.2.3. Тест һәм биремнәр эшләүгә 2 сәгать вакыт бирелә.

2.3. **Татар әдәбиятыннан олимпиада** үз эченә ике юнәлешне ала.

2.3.1. Кызлар татар әдәбиятыннан олимпиадада эзләнү-тикшеренү эше белән катнашалар.

2.3.2. Татар әдәбиятыннан эзләнү-тикшеренү эшенең төп юнәлешләре буларак түбәндәге темалар тәкъдим ителә:

Ш. Камал иҗаты

Я.Агишев иҗаты

Н. Исәнбәт иҗаты

Г. Утыз Имәни иҗаты

К. Насыйри иҗаты

Т. Миннуллин иҗаты

С. Рәмиев иҗаты

Р. Зәйдулла иҗаты

«Ялкын» журналы

М. Кашгарыйның «Диване лөгат әт-төрк» әсәре

Татар әдәбиятында тарихи роман жанры

Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә дини-әхлакый проблемаларның бирелеше

XIX гасыр татар прозасында дин һәм милләт мәсьәләсе.

Әлеге юнәлешләрнең берсен сайлап алып, һәр автор темасын үзе конкретлаштыра, аны өйрәнә, анализлый һәм тикшеренү эшенең төп тезисларын, нәтиҗәләрен чагылдырган 10-12 слайдлы презентация һәм 7-10 минутлык чыгыш әзерли, жюри әгъзаларының сорауларына җавап бирә.

2.3.3. Олимпиада кысаларында дини уку йортларында белем алучы егетләр арасында республикакүләм вәгазь конкурсы уздырыла. Студентлар алдан әзерләнгән вәгазьләрен сөйлиләр. Вәгазь темасы – ирекле. Чыгыш өчен 10-15 минут вакыт каралган. Студентның гомуми образы (тышкы кыяфәте, чыгыш вакытында үз-үзен тотышы) вәгазьчегә булган классик таләпләргә туры килергә тиеш.

2.3.4. Уку йорты татар әдәбиятыннан олимпиадага бары бер генә студентны җибәрә ала. Ул я вәгазь конкурсында, я эзләнү-тикшеренү эшләре бәйгесендә катнаша.

2.4. **Татар халкы тарихыннан олимпиада** тесттан һәм эзләнү-тикшеренү эшеннән гыйбарәт.

2.4.1. Тестны эшләүгә 1.5 сәгать вакыт бирелә.

2.4.2. Олимпиаданың эзләнү-тикшеренү өлеше өчен түбәндәге темалар тәкъдим ителә:

«Татаркино»ның тарихы һәм үсеше (История и развитие «Татаркино»).

Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең тормыш юлы һәм эшчәнлеге (1894-1939) (Жизнедеятельность Сахибгарея Саит-Галиева (1894-1939)).

Коръәннең Гордий Семенович Саблуков (1804-1880) тәрҗемәсе һәм аның миссионерлык эшчәнлегендәге роле (Перевод Корана Гордия Семеновича Саблукова (1804-1880) и его роль в миссионерской деятельности).

М.Г. Худяковның (1894-1936) татар халкының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә керткән өлеше (Вклад М.Г. Худякова (1894-1936) в изучении истории и культуры татарского народа).

М.А. Усмановның тормышы һәм эшчәнлеге (1934-2010) (Жизнь и деятельность М.Г. Усманова (1934-2010)).

Татар профессиональ театрының барлыкка килүе һәм И. Кудашев-Ашказарскийның эшчәнлеге (1884-1942) (Становление татарского профессионального театра и деятельность И. Кудашева-Ашказарского (1884-1942)).

Татар АССРның барлыкка килүе һәм үсеше (Становление и развитие Татарской АССР).

Безнең гаиләбезнең Бөек Ватан сугышында җиңүгә керткән өлеше (Вклад нашей семьи в победу в Великой Отечественной войне).

Фашизмны җиңүдә тыл хезмәтчәннәренең роле (Роль тружеников тыла в победе над фашизмом).

Тәрбия һәм белем бирүдә татар балалар вакытлы матбугатының роле (Роль татарской детской периодической печати в воспитании и образовании).

2.4.3. Әлеге темаларның берсен сайлап алып, автор аны өйрәнә, анализлый һәм тикшеренү эшенең төп тезисларын, нәтиҗәләрен чагылдырган 10-12 слайдлы презентация һәм 7-10 минутлык чыгыш әзерли, жюри әгъзаларының сорауларына җавап бирә.

2.5. Олимпиадада урта һөнәри уку йортларыннан һәр номинациядә – берәр, югары уку йортларыннан ике студентка кадәр катнаша ала.

Әлеге чарада катнашу өчен, кушымтада күрсәтелгән форманы һәм шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык бирүче кушымтаны тутырып, **2024 нче елның 20 нче апреленә кадәр riitatkafedra@mail.ru** адресына җибәрергә кирәк.

2.6. Олимпиаданы оештыру һәм уздыру өчен махсус комиссия, эш группасы, жюри төзелә. Жюри һәр төркемдә җиңүчеләрне һәм призлы урын алучыларны билгели.

2.7. Олимпиаданы оештыру программасы Россия ислам институты, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте тарафыннан тәкъдим ителә.

2.8. Олимпиаданың уздырылу вакытын, урынын оештыручылар билгели һәм хәбәр итә.

## 3. Олимпиаданың нәтиҗәләрен ясау

3.1. Җиңүчеләр, призлы урын алучылар олимпиада нәтиҗәләре нигезендә, һәр юнәлештә аерым билгеләнә.

3.2. Җиңүчеләр, призлы урын алучыларга истәлекле бүләкләр тапшырыла. Һәр катнашучыга сертификат бирелә.

## 4. Олимпиаданы финанслау

4.1. Олимпиада Россия ислам институты бюджеты һәм Россия Федерациясе кануннары белән тыелмаган башка чыганаклар хисабына финанслана.

*Кушымта 1*

| Уку йорты | Юнәлеш | Фамилия, исем, әтисенең исеме | Телефон | Электрон адрес | Эзләнү-тикшерену эшенең темасы (әдәбияттан, тарихтан) Вәгазь темасы | Укытучы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |